ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 127-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, Е.Б. Солтанов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 127-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 27 ноябре
№ 463-VII ДС

127-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
Е.Б. Солтанов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Конституция советы турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» 2023 елның 13 июнендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 48 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле $5^1$ өлеш өстәргә:

«$5^1$. Конституция советы Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларына аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен өйрәнүгә мониторинг үткәрә, аның нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына мәгълүмат җибәрә.»;

2) 11 статьяда:

а) 7 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Татарстан Республикасы норматив хокукый актын, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органы норматив хокукый актын йә аларның аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныган, яки хокукый җайга салудагы өзеклекне юкка чыгару таләбе булган, яки хокукый җайга салуны яисә хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү буенча рекомендацияләр (тәкъдимнәр) бирелгән Конституция советы бәяләмәсе әлеге норматив хокукый актны кабул иткән (чыгарган) орган (вазыйфаи зат) тарафыннан мәҗбүри каралырга, Конституция советы бәяләмәсен алган көннән алып өч ай эчендә Конституция

Советына һәм Татарстан Республикасы Рәисенә аны карау нәтиҗәләре турында хәбәр ителергә тиеш.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 8 өлеш өстәргә:

«8. Конституция советы бәяләмәсендә үзләренә карата хокукый җайга салуны яисә хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү буенча рекомендацияләр (тәкъдимнәр) бирелгән Татарстан Республикасы дәүләт органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары Конституция советы бәяләмәсен алган көннән алып өч ай эчендә Конституция Советына һәм Татарстан Республикасы Рәисенә аны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итәргә тиеш.»;

3) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 статья. **Конституция советы эшчәнлеге турында доклад**

Конституция советы елга бер тапкыр Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына үз эшчәнлеге турында доклад юллый. Доклад Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Конституция советы Рәисе тарафыннан тәкъдим ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – Татарстан Республикасы законы проекты) Татарстан Республикасы Конституция советы (алга таба – Конституция советы) эшчәнлеген камилләштерү, аның вәкаләтләрен киңәйтү максатыннан эшләнде.

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» 2023 елның 13 июнендәге 44-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) 2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Конституция советы «Аерым федераль конституциячел законнарга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 декабрендәге 7-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел законга таянып төзелде, үз эшчәнлеген Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатларында алып баручы даими эшли торган Татарстан Республикасы дәүләт органы булып тора.

Конституция советы эшчәнлегенең төп эш юнәлешләренең берсе гражданнар, оешмалар, дәүләт хакимиятенең, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары гарызнамәләре, мөрәҗәгатьләре буенча бәяләмәләр чыгару юлы белән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвенә тикшерү уздырудан гыйбарәт.

Шул ук вакытта, Конституция советы эшчәнлегендә законнар нигезендә бәйсезлек каралса да, аның эш күләме гарызнамәләр йә мөрәҗәгатьләр булуга бәйле, димәк, яңа дәүләт органы эшчәнлегенең нәтиҗәле булуы турыдан-туры мөрәҗәгать итүче субъектларның активлыгыннан тора.

Хәзерге вакытта Конституция советы норматив хокукый актларга мониторинг ясау тәкъдиме белән чыга алмый.

Әлеге дәүләт органына мөрәҗәгатьләргә бәйле булмаган мондый мониторинг ясау вәкаләте бирелмәү факты күп очракта Конституция советының мөмкинлекләрен чикли һәм бу дәүләт органына куелган максатларга, Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатына ирешүгә комачаулый.

Әлеге проблеманы Конституция советының вәкаләтләр исемлеген норматив хокукый актларга мониторинг ясау өлешендә киңәйтү юлы белән хәл итәргә мөмкин. Закон проектында тәкъдим ителә торган яңа вәкаләт конституциячел-хокукый проблемаларны, шул исәптән гражданнарның мөрәҗәгатьләрендә күтәрелә торган проблемаларны хәл итү юлы булачак.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы законы проекты белән «Татарстан Республикасы Конституция советы турында»Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына Конституция советына Татарстан Республикасы

норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларына аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килүен өйрәнүгә мониторинг үткәрү, аның нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына мәгълүмат җибәрү хокукы бирелү турындагы өлеш өстәлә.

Шулай итеп, Конституция советына югарыда күрсәтелгән норматив хокукый актларга аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәвен тикшерүгә мониторинг үткәрү хокукы бирелү гражданнарның, оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга өстәмә гарантия булачак, демократик җәмгыять үсеше өчен хокукый җайга салуны камилләштерергә ярдәм итәчәк.

Татарстан Республикасында конституциячел законлылыкны ныгыту максатларында эшчәнлек алып бара торган Конституция советының статусын исәпкә алып, аңа тәкъдим ителә торган вәкаләтләрне бирү Татарстан Республикасы Конституциясен, кеше һәм гражданның, оешмаларның төп хокукларын һәм ирекләрен яклауның, Татарстан Республикасы хокук системасында Төп законның югарылыгын хуплауның, шулай ук мөрәҗәгать итү субъектларының түбән активлыгы шартларында аның эшләвен турыдан-туры тәэмин итүнең үтемле алымы булыр иде.

Конституция советы бәяләмәләрен кабул итү тәҗрибәсе күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы норматив хокукый актын, йә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының норматив хокукый актын яки аның аерым нигезләмәләрен карап, Конституция советы еш кына хокукый җайга салуны яисә хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү буенча рекомендацияләр (тәкъдимнәр) бирә. Шуңа бәйле рәвештә закон проекты белән «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 7 өлешенә яңа нигезләмә өстәргә тәкъдим ителә, ул норматив хокукый актны кабул иткән орган (вазыйфаи зат) тарафыннан бәяләмәләрнең мәҗбүри каралырга тиешлеген билгели.

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законында норматив хокукый актны кабул иткән (бастырып чыгарган) орган (вазыйфаи зат) белән элемтәгә керү механизмы булмауга бәйле рәвештә, закон проекты белән Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы әлеге өлешкә норматив хокукый актны аны кабул иткән (чыгарган) орган (вазыйфаи зат) тарафыннан мәҗбүри каралырга, Конституция советы бәяләмәсен алган көннән алып өч ай эчендә Конституция Советына һәм Татарстан Республикасы Рәисенә аны карау нәтиҗәләре турында хәбәр ителергә тиешлек турында яңалык кертелә.

Моннан тыш, закон проекты Татарстан Республикасы Законының 11 статьясына яңа 8 өлеш өстәргә тәкъдим итә, аның нигезендә Конституция советы бәяләмәсендә үзләренә карата хокукый җайга салуны яисә хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү буенча рекомендацияләр (тәкъдимнәр) бирелгән

Татарстан Республикасы дәүләт органы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары Конституция советы бәяләмәсен алган көннән алып өч ай эчендә Конституция Советына һәм Татарстан Республикасы Рәисенә аны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итәргә тиеш.

Закон проектында шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына да үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә, анда Конституция советы тарафыннан кертелә торган докладның Татарстан Республикасында конституциячел законлылык турында түгел, ә Конституция советының үз эшчәнлеге турында булуы билгеләнә.

Тәкъдим ителә торган үзгәрешләр Конституция советының эшчәнлек нәтиҗәләре буенча әзерләнде һәм аның эшчәнлеген хокукый җайга салуны камилләштерү, шулай ук яңа дәүләт органы эшчәнлегенең үтемлелеген арттыруга юнәлдерелә.

**«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы Конституция советы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.